КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 июль г.Казань № 497

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче, 2016 ел, 20 февраль, 103 нче, 2016 ел, 6 август, 536 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба – Министрлык) хезмәткәрләренең чик санын 842,5 берәмлек дип, вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча хезмәткә түләүнең айлык фондын 3 333,2 мең сум дип билгеләргә, шул исәптән:

117 берәмлек – Министрлык аппараты хезмәткәрләре, вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча хезмәткә түләүнең айлык фонды 579,5 мең сум;

725,5 берәмлек – Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләре, вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча хезмәткә түләүнең айлык фонды 2 753,7 мең сум.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турында нигезләмәдә;

1.5 пунктта «Татарстан ур., 55 йорт» сүзләрен «Кремль ур., 16 йорт» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта:

өченче абзацта «һәм хокукый тәэмин итү» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы башкарма хакимиятнең республика органнары норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03<*>).»;

4.1.16 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «башкарма хакимиятнең республика органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин